Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Татар Чаллысы авыл җирлеге составына керүче
Татар Чаллысы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«24» ноябрь 2023ел № 5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Советының 2019 елның 4 октябрендәге 149 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, 2023 елның 24 ноябре 15.00 сәг.Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлегенең Татар Чаллысы авылы гражданнар җыенында «2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авылы җирлегенең Татар Чаллысы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, билгеләргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы? дигән сорау каралды һәм йомгаклау беркетмәсе төзелде

**Авыл җирлеге территориясен төзекләндерү:**
- Урам яктырткычларын урнаштыру
- Агачларны кисү;
- кече архитектура формаларын һәм балалар спорт җиһазларын сатып алу һәм урнаштыру,
- Материалны монтажлау һәм сатып алу ("Чаллы" елгасына металл баскыч ясау өчен)

Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
Суга батыру насосын сатып алу,

**Юл эшчәнлеге:**
җәйге һәм кышкы чорда юлларны карап тоту

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 227 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 181 граждан.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ" - 181 граждан тавыш бирде;

"ЮК" - 0 граждан

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авыл җирлегенең Татар Чаллысы авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

җыенында «2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авылы җирлегенең Татар Чаллысы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, билгеләргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы? дигән сорауга карарны танырга.

**Авыл җирлеге территориясен төзекләндерү:**

- Урам яктырткычларын урнаштыру
- Агачларны кисү;
- кече архитектура формаларын һәм балалар спорт җиһазларын сатып алу һәм урнаштыру,
- Материалны монтажлау һәм сатып алу ("Чаллы" елгасына металл баскыч ясау өчен)

Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

Суга батыру насосын сатып алу,

**Юл эшчәнлеге:**

җәйге һәм кышкы чорда юлларны карап тоту

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында « Татар Чаллысы авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы

Татар Чаллысы авыл җирлеге башлыгы Т.П. Кузнецова.